**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2024 № 1336

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясен төзү турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 1993 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карарлары, «Татарстан Республикасы эвакуация комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 24 июлендәге 620 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә эвакуация чараларын планлаштыру, әзерләү һәм уздыру эшен оештыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясен төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясе турында нигезләмә (1нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясе составы (2нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясе рәисенең функциональ бурычлары (3нче кушымта).

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

– Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясен төзү турында» 2023 елның 08 ноябрендәге 1415 номерлы карары;

– Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясен төзү турында» 2023 елның 08 ноябрендәге 1415 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 27 маендагы 559 номерлы карары;

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин